**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

«Үтәтү эшен алып бару турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү зарурлыгы хакында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Үтәтү эшен алып бару турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү зарурлыгы хакында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күрсәтелгән мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 18 ноябре
№ 1701-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2022 елның 18 ноябрендәге
1701-VI ДС номерлы карарына
кушымта

Хөрмәтле Вячеслав Викторович!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына мобилизация буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан балигъ булмаганнарны карап тоту өчен үтәтү эшен алып бару турындагы законнар нигезендә алимент түләнә торган балаларның аналарыннан мөрәҗәгатьләр керә.

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты указы нигезендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр статусына ия. Күрсәтелгән категориядәге гражданнарның акчалата тәэминаты хәрби хезмәткәрләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1908 номерлы карары белән балигъ булмаган балаларга алимент тотыла торган хезмәт хакы һәм башка керем төрләре исемлегенә кертелгән акчалата тәэминаты (акчалата тулы кереме) дәрәҗәсенә туры килә.

Хәрби хезмәткәрләрдән алимент түләттерү үтәтү эшен алып бару турындагы законнар нигезендә башкарыла. Шул ук вакытта «Үтәтү эшен алып бару турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы нигезендә үтәтү эше, шул исәптән алимент түләтү буенча, бурычлы зат Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә, Россия Федерациясе законнары нигезендә булдырылган башка гаскәрләрдә, хәрби формированиеләрдә һәм органнарда катнашса, бурычлы зат гадәттән тыш яисә хәрби хәл, кораллы конфликт шартларында бурыч үтәсә, йә шундый ук шартларда булган алимент алучы үтенече буенча суд пристав-башкаручысы тарафыннан туктатылырга тиеш.

Шундый ук нигезләмәләр күрсәтелгән статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында да бар, алар нигезендә үтәтү эшен алып бару чакырылыш буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы, Россия Федерациясе законнары нигезендә булдырылган башка гаскәрләрдә, хәрби формированиеләрдә һәм органнарда катнашучы бурычлы затның үтенече белән туктатылырга мөмкин.

Безнең фикеребезчә, күрсәтелгән нормалар, алимент түләтү буенча үтәтү эшенә карата кулланылган очракта, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балигъ булмаган балаларын һәм хезмәткә

яраксыз мохтаҗ ата-аналарын карау бурычын үтәтергә комачаулый, санап үтелгән категорияләр өчен даими рәвештә акча алып тору аларның төп яшәү чыганагы булырга мөмкин.

Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен, хөрмәтле Вячеслав Викторович, «Үтәтү эшен алып бару турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законга югарыда күрсәтелгән 40 статьяның 1 өлешендәге 3 пункты һәм 2 өлешендәге 3 пункты нигезләмәләренең Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарыннан алимент һәм алимент бурычын түләттерү очрагына кагылмавын күздә тоткан үзгәрешләр кертү мөмкинлеген карауны сорыйбыз.